**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423732, Түке авылы,
Илтимер ур., 2 нче йорт.
Тел.3-44-61

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423732, село Тюково,
ул. Илтимерова,дом 2,
Тел. 3-44-61

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№2 03.11.2020ел.

Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлегенең Чәчер, Зөбәер, Түке торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Түке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Түке авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Чәчер авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нче елның 13 ноябренә билгеләргә.

1.1. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Зөбәер авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нче елның 13 ноябренә билгеләргә.

1.2. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Түке авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нче елның 20 ноябренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2021 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, аларның саны җирлек халкының гомуми санынннан 30 процентган да артмый., һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

Авыл җирлеге чикләрендә җирлектәге халыкны су белән тәэмин итү:

Авыл җирлеге чикләрендә төзекләндеру эшләрен оештыру:

Авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Авыл җирлеге чикләрендә халыкны электр хэм су белән тәэмин итуне оештыру.

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Чәчер авылы, Узәк урамы, 31йорт, Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Зөбәер авылы, Узәк урамы, 32йорт, Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Түке авылы, Ленин урамы,61/ 2йорт,

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Түке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.М.Нуртдинов